**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"23" ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге территорисендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- Кышлау авылы Чапаев урамына 500 метр арадан чишмә суын китерү;
- торбалар сатып алу һәм салу, насос сатып алу.

2) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Кышлау авылы территориясен чистарту.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлегенең Кышлау авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Кышлау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.

Совет
сельского
поселения
Кышлау
авыл җирлеге